**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 84** **«16» июнь 2023 ел**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге
Советының 2014 елның 27 февралендәге 106 номерлы
«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Бохарай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 6 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Бохарай авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең 2014 елның 27 февральдәге 106 номерлы “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында” нигезләмәнең 19 статьясындагы 3 өлешенә үзгәреш кертеп, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)»сүзләренә алмаштырырга
2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында, авыл җирлекләре территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе Е.В. Груздева